**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**башкарма комитеты**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**«11» ноябр 2018ел** **№ 329**

Азнакай муниципаль районының җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен халык дружиналары әгъзаларын бүләкләү турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Азнакай район Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәрендә тәртип саклау җәмәгать пунктларын төзү турында» гы 25.08.2015 ел, № 387-55 карарын үтәү йөзеннән (25.08.2015 ел, №387-55, 07.12.2015 ел, №22-3, 22.08.2015 ел) Азнакай муниципаль районы территориясендә җәмәгать тәртибен саклауны гамәлгә ашыруда катнашучы халык дружиналары әгъзаларын бүләкләү максатларында **карар бирәм:**

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен халык дружиналары әгъзаларын бүләкләү турында нигезләмәне 1нче кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru. һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Җитәкче А.Х.Шәмсетдинов

1 нче кушымта
Азнакай муниципаль районы Башкарма
комитеты карарына
«______»__________2018 №_____

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
районының җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан
халык дружиналары әгъзаларын бүләкләү турында
нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының халык дружиналары әгъзаларын бүләкләү аларның иҗтимагый эшчәнлеген стимуллаштыруга юнәлдерелгән һәм елга бер тапкыр башкарыла. . Ел саен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының 50 халык дружинасы әгъзасы бүләкләнергә тиеш.

2. Бүләкләү Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының җәмәгать тәртибен саклауны тормышка ашыруда катнашучы халык дружинасының һәр әгъзасының иҗтимагый эшчәнлегенә индивидуаль бәя бирү нигезендә башкарыла.

3. Бүләкләү дигәндә түбәндәгеләр күздә тотыла:
- бассейнга бару өчен бушлай еллык абонемент;
- ябык боз шугалагына йөрү өчен бушлай абонемент.

4. Бүләкләү өчен Татарстан Республикасында халык дружиналары һәм хокук саклау юнәлешендәге иҗтимагый берләшмәләр реестрына кертелгән Азнакай муниципаль районы халык дружиналары әгъзалары кандидатлар булып тора.

5. Азнакай муниципаль районы халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча штаб начальнигы кандидатны бүләкләү өчен тәкъдим әзерли һәм Азнакай муниципаль районы халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү штабына 1нче кушымта нигезендә җибәрә.

6. Бүләкләү өчен кандидатлар Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәре халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча штаб утырышында карала һәм раслана. Кандидатларны бүләкләү турында карар Азнакай муниципаль районы халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча штаб утырышында катнашучыларның күпчелек тавыш белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

7. Карар кабул иткәндә түбәндәге критерийлар исәпкә алына:
1) дежурлыкка чыгуның даими булуы;
2) массакүләм чаралар үткәргәндә халык дружинасы әгъзасының катнашуы;
3) административ хокук бозуларны ачыклау һәм булдырмау;
4) җинаятьне ачуда хокук саклау органнарына ярдәм күрсәтү.

8. Азнакай муниципаль районының халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча штаб карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, ул өч көн эчендә Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәре халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча начальник, начальник урынбасары, секретаре һәм штаб әгъзалары тарафыннан имзалана.

9. Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәре халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү штабы карары Азнакай муниципаль районының җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен халык дружиналары әгъзаларын бүләкләү өчен нигез булып тора.

10. Азнакай муниципаль районында халык дружиналары эшчәнлеген координацияләү буенча штаб үз утырышларына хокук саклау органнары, дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләрен һәм халык дружиналары командирларын чакырырга хокуклы.

Азнакай муниципаль районының
җәмәгать тәртибен саклауда актив
катнашкан халык дружиналары
әгъзаларын бүләкләү турында
Нигезләмәгә 1 нче кушымта

## Азнакай муниципаль районының җәмәгать тәртибен саклауда актив катнашкан өчен халык дружиналары әгъзаларын бүләкләү турында премия бирүгә тәкъдим итү

Кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме
_______________________________________________

Туган көне, ае, елы ___________________________

Яшәү урыны адресы ___________________________

Халык дружинасы отрядының исеме һәм эшләү урыны___________________________
_______________________________________________

Татарстан Республикасында халык дружиналары һәм хокук саклау юнәлешендәге иҗтимагый берләшмәләр реестрына кандидатны кертү датасы (көне,ае, елы)___________________________
Эш урыны, вазыйфасы ___________________________

Соңгы елда бүләкләк тапшырыла торган конкрет казанышларны күрсәтеп характеристика: Халык дружинасы әгъзасының массакүләм чаралар үткәргәндә катнашуы:
Дежурлыкка чыгуының даимилеге:

_______________________________________________
_______________________________________________

Административ хокук бозуларны ачыклау һәм булдырмау:

_______________________________________________
_______________________________________________

Җинаятьне ачуда хокук саклау органнарына ярдәм күрсәтү

_______________________________________________
_______________________________________________

Башка казанышлар:

_______________________________________________
_______________________________________________

Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәре халык дружиналары
эшчәнлекне координацияләү буенча штаб начальнигы

__________ ________________

(имза)